РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«Татарстан социаль-икътисадый өлкәне үстерүне дәвам итүгә иреште»

> 2

ТИНЧУРИНДА – ПРЕМЬЕРА!

Сатирик комедиядә нинди күренешләр фаш ителә?

> 3

ТИМЕР «КОШ»ЛАР

Татарстан ил авиациясе үсешенә өлеш кертте һәм кертә

> 3



БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 38 (29005) | Шимбә | 18 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

БАРМАК АША КАРАМАГЫЗ!

МӘКТӘП АШХАНӘЛӘРЕНДӘГЕ ХИЛАФЛЫКЛАР ТУРЫНДА

Куллану вакыты чыккан тәм-том, тәлинкәләргә тиешле ризыкны салып бетермәү, товар китерүчеләрнең намуссызлыгы, өстәл өсте пычраклыгы, таләпләр үтәлмәгән ашханәләр... Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының Казанның Азык-төлек, туклану һәм социаль туклану департаментында узган күчмә утырышында ашханәләрдәге вазгыять, туклануны яхшырту юллары турында фикер алыштылар.

Утырыш алдыннан депутатлар Департаментның җитештерү цехлары һәм продукция саклау складлары белән танышты. Предприятиенең генераль директоры, депутат Рима Мөхәммәтшина белдергәнчә, складларда ике атналык продукция запасын саклау мөмкинлеге бар. Предприятие көнгә 226 тонна полуфабрикат җитештерә, 300 мең кешене ашата.

Быелгы уку елында республикада 1410 мәктәп эшли. Анда 483 мең бала белем ала. Шуларның 46,1 проценты – башлангыч сыйныф укучылары. Мәктәп ашханәләрен төзекләндерү һәм җиһазландыруга республика казнасыннан ел саен 1 миллиард сум акча бүлеп бирелә. 2021 елда әлеге акчага – 196, узган ел 167 мәктәптә ремонт эшләре башкарылган, быел 143 азык-төлек блогын ремонтларга җыеналар. 5–11 сыйныф укучыларына туклану өчен республика бюджетыннан субсидия бирелә. Былтыр ул бер балага көнгә 8,3 сумны тәшкил иткән.

– Әти-әниләр арасында сораштыру уздырган идек. Аларның 77,3 проценты мәктәп ризыгыннан канәгать булуын белдергән. Идел буе округы белән чагыштырганда, бу – яхшы күрсәткеч. Әмма тынычланырга ярамый. Әлегә әти-әниләрнең 23 процентка якыны канәгать түгел, – дип белдерде Роспотребнадзорның республика идарәсе җитәкчесе урынбасары Любовь Авдонина.

Сораштыруда катнашучылар ризыкның кайнарлыгына, күләменә игътибар итәргә кушкан. Озын чиратларда басып торып, балалар ашарга өлгермичә кала икән. Вегетариан меню кертергә дигән тәкъдимнәр дә бар.

Любовь Авдонина белдергәнчә, яңа СанПиН кагыйдәләре буенча укучыларга сосиска ашату рөхсәт ителми. Ә балалар аны яратып ашый. Нишләргә? Белгечләр моның җаен тапкан. Чаллы һәм Алабугадагы ит комбинатларына үз продукцияләреннән сыйфатлы сосискалар җитештерүне йөкләгән. Хәзер ашханәләрдә укучыларга атнага бер мәртәбә шуны тәкъдим итәләр.

Роспотребнадзор белгечләре мәктәп ашханәләрендә 943 тикшерү уздырган. Шуның 83 процентында җитешсезлекләр табылган. Любовь Авдонина, узган ел белән чагыштырганда, хилафлыкларның күпкә кимүен әйтте. Әмма ризык суынган, тәлинкәдәге ботканың күләме ким булган очраклар әле дә бар. Хәтта ризыктан микроблар табылган очраклар да юк түгел. Казан, Чаллы, Әлмәт, Сарман, Тукай, Ютазы, Балык Бистәсе, Югары Ослан районнарының мәктәп ашханәләрендә шундый күңелсез күренешләр теркәлгән. Искергән продукцияләр дә табыла тора. 10 мәктәптә куллану вакыты чыккан мармелад, атланмай, солы ярмасы, әфлисун, катырылган җиләкләр, сохари ашханәдән алынган.

Узган ел продуктлар китерүдә 44 хилафлык очрагы теркәлгән. Әтнә районының Комыргуҗа мәктәбендә – бәрәңгедә, Казандагы 28 нче гимназиядә чөгендердә нитрат тапканнар. Аксубай районының Савгачевская мәктәбенә китерелгән сыер итендә антибиотик (окситетрациклин) ачыкланган. Мондый күренешләрне авыл мәктәпләренә товарны алдан күпләп китерүгә бәйләп аңлаттылар. Район җитәкчеләренә һәм Мәгариф министрлыгына продукцияне тиешле күләмдә һәм кирәкле вакытта китерүне көйләргә туры киләчәк.

Әнә АБК – Пэймент туклану операторына карата хәтта 498 кисәтү ясалган. 16 мәктәп ашханәсеннән 143 кило продукция алынган. Медицина белешмәсе булмаган хезмәткәрләр, пычрак цехлар, табак-савытлар, порция күләмен киметү, суык ризык, ашамлыкларны дөрес сакламау... Менә шулар өчен дәгъвалар белдерелгән.

– Намуссыз товар җитештерүче һәм китерүчеләрнең исемлеген барлыйбыз Тиздән аларны идарәнең сайтына урнаштырачакбыз, – диде Любовь Авдонина.

Любовь Авдонина шулай ук Аксубай районының Иске Чуваш Әдәмсуы авылы мәктәбенең буфеты техник-санитар таләпләргә җавап бирмәвен дә әйтте. 1960 нчы елда төзелгән уку йорты бу. Анда 4 бала укый. «Тәрәзә рамнары черек, идәннәрендә – ярыклар. Өстәлләрдә – тычкан «йомыш»лары. Ашханә 90 тәүлеккә ябылды. Балаларга ризык китерелә, гигиена таләпләре үтәлә», – диде ул. Чүпрәле районының Түбән Чокырча мәктәбенең склад диварлары күгәрек белән капланган булган. Шул сәбәпле, аны да вакытлыча ябып торганнар. Ремонт эшләре башкарылып, җилләтү юллары көйләнгән. Кимчелекләрне төзәтү өчен Роспотребнадзор вәкилләре бару кирәк булган микәнни?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Солдатлар ялга кайтты

Мобилизацияләнүчеләрнең беренче төркеме махсус хәрби операция зонасыннан Казанга ике атналык ялга кайтты. Республика башкаласына шулай ук Башкортстан, Мари Иле, Чувашия һәм Удмуртиядән чакырылган хәрби хезмәткәрләр дә кайтып төште. Казан мэриясенең матбугат хезмәте хәбәренә караганда, егетләр берничә тәүлек вакытын юлда уздырган. 4 автобуска төялгән солдатларны Үзәк стадион тирәсендә туганнары һәм якыннары каршы алды.

Хәрбиләр әйтүенчә, алар белән әйбәт инструкторлар эшләгән. Солдатлар кирәкле барлык күнекмәләргә өйрәтелгән. Егетләргә алгы сызыкта бик тә ярдәм иткән бу. «Иң мөһиме – сынауларның барысын да җиңеп, тыныч күңел белән өйләребезгә әйләнеп кайта алуыбызга ышану», – ди солдатлар.

Гадиләштергәннәр

Татарстан Күпфункцияле үзәге (КФҮ) яшәү урыныннан читтә дә муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеге тудырган.

Казанда яшәүче кеше, әйтик, Питрәч районында шәхси йорт төзи башлавы һәм төзелешне тәмамлавы турында белдерү кәгазен тапшыру өчен, моңа кадәр бары тик шул районның башкарма комитеты яки КФҮ филиалына гына мөрәҗәгать итә алса, хәзер аны теләсә кайсы филиалда кабул итәчәкләр. Архив документлары, белешмәләр, башка документлар өчен дә, мәсәлән, Лениногорскидан Әгерҗегә бару кирәкми. Аларны үзеңнең яшәү урыныңдагы КФҮ филиалы аша гына алырга мөмкин.

Өстәвенә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен, гариза тапшырылган КФҮ филиалыннан тыш, теләсә кайсы филиалдан алу мөмкинлеге ачылган. Республикада барлыгы 61 КФҮ филиалы эшләп килә.

Башкарма комитетлар белән КФҮ филиаллары арасында электрон документ әйләнешен оештыру нәтиҗәсендә муниципаль хезмәтләрдән файдалану әнә шулай гадиләштерелгән. Ләкин шунысы бар: документка вазыйфаи затның шәхсән имза куюы таләп ителмәгән хезмәтләргә генә кагыла бу. Әйтик, җир кишәрлеген милеккә алу өчен, бары тик бу кишәрлекнең урнашу урыны буенча башкарма комитетка яки КФҮ офисына гына мөрәҗәгать итеп була.

Бездә эш тапканнар

Татарстанда Донецк, Луганск Халык Республикаларыннан, Запорожье һәм Херсон өлкәләреннән күченүчеләргә эшкә урнашырга ярдәм итәләр. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, республикада аларны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру өчен 11 пункт булдырылган. Мәшгульлек үзәкләре белгечләре – эшкә урнашу, социаль яклау органнары хезмәткәрләре исә бер тапкыр бирелә торган түләү алу өчен документлар рәсмиләштерүгә бәйле киңәшләрен бирә. Моннан тыш, вакансияләр ярминкәләре, эш бирүчеләр белән очрашулар оештырыла.

Күченүчеләр арасыннан 551 кеше эшкә сәләтле. Шуның 298е вакытлыча урнаштыру пунктларында яши. 455 кеше эшкә урнашырга ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать иткән. Алар арасыннан12се – инвалид һәм 30ы – пенсионер.

Бүгенгә 354 кеше, ягъни әлеге мәсьәләдә булышып җибәрүне сораучыларның 77,8 проценты эш тапкан.

Язгы сәүдә гөрли

Бүген Казанда 15 мәйданчыкта язгы ярминкәләр башланды. Аларга республиканың 22 районыннан 18 оешма үз продукциясен китергән. Авыл хуҗалыгы ярминкәләре башкалабызның барлык районнарында уздырыла. «Салават күпере» микрорайонында яшәүчеләр өчен Осиново бистәсендә «Радужный» сәүдә үзәгенең машина кую урынында сәүдә рәтләре эшли.

Язгы ярминкәләрнең ачылачагы турында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров 7 март көнне белдерде. Көзге ярминкәләр исә 24 декабрьдә тәмамланган иде. Анда шәһәр халкына 787,8 млн сумлык товар тәкъдим ителде. Ярминкәнең бер көнендә аграрийлар уртача 49 миллион сумлык товар саткан.

Юл хәлләре

Руль кем кулында?

Кыска гына вакыт эчендә ике «җәяүле» машина тәгәрмәче астында калды... Үзен исерек килеш машина йөртүче сыйфатында сынап караган Олеся Колесникова эшне шулай кыска тотты. Бәхеткә, күзләрендә – хәмер кулланган килеш руль артына утыручының ниләр күргәнен, кичергәнен тоярга мөмкинлек биргән махсус күзлек, тәгәрмәч астында калган «җәяүле» урынына – конуслар.

Исерек килеш машина йөртүнең аянычлы нәтиҗәләренә багышланган «түгәрәк өстәл» башланыр алдыннан журналистларга бу күренешне үзләре сынап карау мөмкинлеге тудырылды. Егерме еллык машина йөртү тәҗрибәсе булган Олеся машинадан төшүгә авыр сулап куйды. «Бөтен дөнья кап-караңгы, берни күренми, шулкадәр куркыныч. Машинаны бөтенләй тоемламыйсың, баш эшләми. Баштарак тапшыру тартмасын таба алмый тилмердем. Конусларны кеше дип күз алдына китерсәң, мин бер-бер артлы ике җәяүлене бәрдергән булып чыгам. Аллам сакласын, – дип хис-кичерешләре белән бүлеште ул.

Кызганыч, көндәлек тормышта мондый аяныч очраклар даими күзәтелә. Саннар да шул хакта сөйли. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы ЮХИДИ идарәсенең юл-патруль хезмәте инспекторы Ленар Садыйков сүзләренә караганда, узган ел республикада исерек килеш машина йөртүчеләр гаебе белән 256 юл һәлакәте килеп чыккан. Анда 56 кешенең гомере өзелгән, 336 кеше имгәнгән.

– Татарстан юлларында кеше үлеменә китергән һәр алты фаҗиганең берсендә рульгә исерек килеш утыручылар гаепле. Узган ел исерек килеш машина йөрткән 13 меңнән артык кеше тоткарланды. Шуларның меңнән артыгы инде икенче тапкыр тотылган. Алар җинаять җаваплылыгына тартылды. Суд аларны мәҗбүри эшләргә җәлеп итәргә, штраф салырга яки ирегеннән мәхрүм итү карары чыгарырга мөмкин, – ди Ленар Садыйков.

«Яшел түгәрәк» социаль инициативалар үсеше үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешма җитәкчесе Юлия Денисова фикеренчә, мондый фаҗигале очракларны булдырмас өчен, «хәмернең рөхсәт ителгән күләме» дигән төшенчәне юкка чыгарырга кирәк. Машина йөртергә өйрәтү мәктәпләренә дә шундый яңалык кертү яклы ул.

– Рульгә утыручыда, «рөхсәт ителгән хәмер күләме» дигән сүзне ишетүгә, үзеннән-үзе фәлән кадәр куллансам, исерек килеш тә машина йөртергә ярый икән дигән уй туа. Бу – зур хата. Узган ел исерек килеш юл һәлакәте китереп чыгарган машина йөртүчеләрнең 42 проценты «җиңелчә» исерек хәлдә булган, – ди Денисова.

Мондый фаҗигаләрне булдырмау максатыннан, оешма белгечләре 2013 елдан «Автоаеклык» проектын тормышка ашыра башлаган. Ул хакимият органнары, автомәктәпләр, вузлар, медицина, белем бирү оешмалары, эшмәкәрләр белән берләшеп, исерек килеш машина йөртү гадәтен юкка чыгару, юлларда хәмергә бәйле аянычлы очракларны киметүне күздә тота. Хәзерге вакытта әлеге проект Россиянең 16 төбәгендә тормышка ашырыла. Быелдан башлап ул Татарстанда да гамәлгә керәчәк. «Түгәрәк өстәл» барышында «Татспиртпром» оешмасы белән «Яшел түгәрәк» социаль инициативалар үсеше үзәге» коммерцияле булмаган автоном оешмасы арасында килешү имзаланды.

– Әлеге проект кысасында автомәктәпләр программасына «Автоаеклык» дигән бүлек кертеләчәк. Ил күләмендә 250 автомәктәптә укыган 45 меңнән артык кеше бу курсны тыңларга өлгерде инде. Ул Татарстанда да уңышлы гына тормышка ашырылыр дип өметләнәбез, – диде Юлия Денисова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Хәзер бизнесны үстерү һәм аны киңәйтү өчен мөмкинлекләр, перспективалар тагын да күбрәк, һәм Россия бизнесы шуларны кулдан ычкындырмаска тиеш. Илгә карата санкцияләр басымы турында әйткәндә, башкаларга чокыр казыма, үзең шунда төшәрсең, дигән мәкаль искә төшә. Шул күзәтелә дә кебек.

(Россия сәнәгатьчеләр һәм эшмәкәрләр берлеге съездындагы чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – ЮЛ-ТРАНСПОРТ ҺӘЛАКӘТЛӘРЕ

АВАРИЯЛӘР САНЫ*

2012 ел >> **204 мең** очрак

2017 ел >> **169 мең** очрак

2022 ел >> **127 мең** очрак

79 меңе – шәһәрләрдә / 17 меңе – авыл җирлекләрендә / 31 меңе – халык яши торган пунктлардан тыш территорияләрдә

*ЮХИДИ хезмәте мәгълүматларына нигезләнеп

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кечкенә дә төш кенә

Икътисадый үсеш-алгарышны, тормыш сыйфатын, гомумән, заманчалыкны югары технологияләрсез күз алдына да китереп булмый хәзер. Ә технологияләрнең үзләрен электроникасыз, төгәлрәк әйткәндә, микроэлектроника дип аталган, бер үк вакытта фән дә, шактый катлаулы сәнәгать тармагы да булган өлкәсез күрү кыен. Цифрлы технологияләр, дип сөйләшәбез икән, анысы да – шул ук чиплар, микроэлектроника инде.

Без белем алып йөргән дәверләрдә «чип» дигән, кечкенә пластинканы аңлаткан инглиз сүзе әле юк иде. Ә микросхема дигән, төшенчә генә түгел, микросхемалар үзләре дә бар иде. Бүгенге белән чагыштырганда күпкә гадирәкләре, әлбәттә. Кечкенә пластмасс корпус, корпустан чыгып, аска карап торган 14 яисә 16 нечкә калай «тәпи». Нинди дә булса җиһазның электрон өлешен ясаганда, тәпиләр платодагы кечкенә тишекләргә кидертелә, тишекләр аша сызык рәвешендәге күпсанлы «юл»ларга тоташа. Тәпиләр, сызыклар буйлап, җиһаз эшләгән мәлдә, электр сигналлары, төрле импульслар чабыша. Кайсы эчкә кереп кача, кайсы чыга да башка детальләргә – диод, конденсаторларга, бүтән микросхемага юнәлә. Бер кечкенә платоны алганда да, йөзәрләгән шундый бәйләнеш һәм хәрәкәт.

«Микросхема эчендә ни-нәрсә соң?» – диярсез. Дөрес сорау бу. Аның эчендә кечкенәдән-кечкенә хикмәт – транзисторлар мыжгып тора. Баштан ук искәртергә оныткамын: үземә бик тә якын өлкәгә кереп китүнең сәбәбе бар, «транзистор» дип аталган электрон нәмәрсә уйлап табылуга шушы көннәрдә нәкъ 75 ел тулды.

Бүген һич шикләнми әйтеп була: шул кечкенә дә төш кенә структура уйлап табылмаса, хәзерге дөнья гел башка буласы иде. Һәрберебезнең кесәсендә йөргән смартфон дип аталган күпфункцияле җайланманы күрмәсебезне әйткән дә юк, андый җиһазның күпкә гадирәге дә ике ятып, бер төшебезгә дә кермәс иде. Компьютер, видеокамералар, автомобильләрдәге кырыкмаса-кырык төрле электрон опцияләр, предприятиеләрдәге күпсанлы станоклар, күптин-күп төрле көнкүреш җиһазлары – берсе дә булмас иде. Ни генә димә, аларның барысында да без әйткән электрон элемент, аерым-аерым булсын, күмәкләп булсын, ифрат та киң кулланышта. Шул ук өй телефоннары элек барысы да дисклы иде. Тиешле номерны без дөбер-шатыр диск әйләндереп җыйдык. Бераздан аларның төймәлесе чыкты. Транзистор уйлап табылмаган, алар нигезендә микросхемалар җитештерелә башламаган булса, без хәтта төймәле өй телефонын да күрмәс идек. Чөнки сүтеп караганда, анда да берничә микросхемага юлыгабыз.

14–16 «тәпи»ле «борынгы» микросхемаларда бер-берсе белән кирәгенчә тоташтырылган транзисторлар, ике төрле ярымүткәргечне бер-беренә «ягып» ясалган, электрон күчеш (p-n переход) дип аталган хикмәтләр йөздән дә артмады. Бүгенге чипларда аларның саны, әйтергә генә җиңел, 10 миллиардка (!) якынлаша. Тирәнгә кереп, укучының башын катырасым килми, әйтәсе килгән төп сүзем шул: p-n күчеш, ике шундый күчештән торган транзистор уйлап табылганнан бирле, ул теләсә нинди электрониканың чишмә башы, база элементы, нигезе булып кала…

Кайчандыр борынгы шумерлар тәгәрмәч уйлап тапкан. Кешелек дөньясы үсеше дигәндә, тәгәрмәчнең әһәмияте әйтеп бетергесез дәрәҗәдә зур. Колумбка чаклы ничә мең ел яшәгән Америка цивилизацияләренең аны уйлап табарга башы, акылы җитмәгән. Шул сәбәпле үсештә Иске дөньядан – Евразия кыйтгасыннан нык артта да калганнар. Тәгәрмәчсез дөнья бүген дә сансыз. Барсак та, кайтсак та, һәммәбез – шуның өстендә. Транзистор – XXI гасыр тәгәрмәче. Дөресрәге, аны кулланып тудырылган катлаулы чиплар – шул ук микропроцессорлар – бүгенге кешелекнең төп казанышы дисәк, арттыру булмас. Чиплар – бүгенге технологик алгарышның, сәнәгать кенә түгел, икътисад пирамидасының да очында торган затлы ачыш һәм табышыбыз.

Чиплар куелмаган көнкүреш җиһазлары (сугыш коралларын әйткән дә юк) көннән-көн кими барганда, күп дәүләтләр, шул исәптән Россия дә, аларны үзендә җитештерү турында ныклап уйлый башлады. Уйларсың да, дөнья бүген бер дә тыныч түгел бит. «Халыкара кооперация» дигән багланышларның да исеме генә калып бара. Безнең ил дигәндә, бигрәк тә. Хәзерге көндә чипларны, шул ук микропроцессорларны санаулы дәүләтләр генә җитештерә. Заман таләпләренә җавап бирә торган микросхемаларның 80 процентка якынын Тайвань ясый. АКШ, Кытай, Көньяк Корея кебек илләрдә, Европа дәүләтләренең кайберләрендә чиплар ясау җайга салынган. Ни кызганыч, бу юнәлештә Россия һаман да күзәтүче ролендә калып килә. Безгә дөньяда җитештерелгән чипларның нибары 1 проценттан да кимрәге туры килә – Мәскәү янындагы Зеленоград дигән шәһәрдә бердәнбер шундый заводыбыз бар. Аның да куәте шактый түбән, шул ук Тайваньдагы бер TSMC компаниясе генә дә микросхемаларны без ясаганнан 15 тапкыр күбрәк ясый.

«Мондый көнгә ничек төштек?» дигән сорауга җавап билгеле дә кебек. Шул ук Советлар Союзында, артык алдынгы кимәлдә булмаса да, электроника сәнәгате бар иде. Аннан соң килгән дәвердә безне дөрес булмаган икътисадый сәясәт, төгәлрәк әйткәндә, һаман да шул чималчылык аздырды. «Нәрсәдер җитештереп, булмаганны булдырып мәшәкатьләнмик, баш катырмыйк, нефть долларларына барысын да сатып алып була бит», – дигән тезис, электроника дигәндә дә, башка хәтсез юнәлешләрдә дә көймәбезне комга шактый тиз терәтте. Елга булып аккан валютага күпме җиһаз сатып алып, күпме завод торгызып була иде югыйсә. Заманча чиплар, шул ук микропроцессорлар җитештерүдә кулланыла торган җиһазларны Европа илләре ясаганлыктан һәм санкцияләр сәбәпле, без бүген бөтенләй гаҗизлектә. Белгечләр әйтүенчә, җиһазлар сатып алыр мөмкинлек булганда да, андый заводны корыр, эшләтеп җибәрер, беренче продукция алыр өчен ким дигәндә 1 триллион сум акча кирәк. Икътисадый, сәяси вазгыять тотрыксыз булып, чикләүләр якадан алганда, кем, кайсы корпорация андый чыгымнарга барыр, тәвәккәлләр икән?..

Ил җитәкчеләре әледән-әле Россиянең суверенлыгын ныгыту зарурлыгы хакында белдерәләр. Тик менә үзендә югары технологияләр тудырмаган, электроника сәнәгатен тиешенчә үстермәгән ил, күпме генә теләсә дә, тулы суверенлыкка ия ил була алмый. Башка дәүләтләргә бәйлелек саклый. Дөньялар кайчан да булса тынычланыр, яхшырыр дип өметләник. Шул вакытлар җиткәч, ихтимал, бүгенгедән сабак алмый калмабыз.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЭШЕ БАРНЫҢ АШЫ БАР

Яңа эш урыннары булдыру, инвестицияләр җәлеп итү, икътисадны үстерү. Самарада Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко үткәргән киңәшмәдә Идел буе федераль округына керүче төбәкләргә әнә шундый бурычлар билгеләделәр. Чарада Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Киңәшмәдә кураторлык институты кысасында, Идел буе федераль округында алга китешле проектларны тормышка ашыру турында сөйләштеләр. Вице-премьер билгеләп үткәнчә, Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән барлыкка килгән кураторлык институты төбәкләрдәге проблемаларны тагын да яхшырак аңлау мөмкинлеге бирә һәм илдә алып барылган төбәкләр үсеше сәясәтенең бердәмлеген ныгыта.

Узган ел проектларны тормышка ашыру йомгаклары турында сөйләгәндә, Дмитрий Чернышенко Идел буе федераль округының алдан фаразланган нәтиҗәләргә ирешү күрсәткече буенча дүртенче урында булуын билгеләде.

– Кураторлык институты кысасында тормышка ашырылучы проектларның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген күрәбез. Бу – проектларны тормышка ашыру даими контрольдә торган төбәкләрнең тырыш хезмәте нәтиҗәсе. 2022 елда Идел буе федераль округында 22 меңнән артык эш урыны булдырылган, җәлеп ителгән инвестицияләрнең гомуми күләме 165 миллиард сумнан артып киткән. Хәзер гамәлдә булган чикләүләр эш планнарына үзгәрешләр кертүне таләп итә. Сүз, беренче чиратта, импортны алмаштыру һәм Президент Владимир Путин кушуы буенча технологик суверенитетка ирешү турында бара, – диде ул.

Дмитрий Чернышенко Татарстан, Мари Иле, Мордовия, Пермь крае һәм Саратов өлкәләрендәге идарәче командаларның эшен югары бәяләде.

Аның әйтүенчә, фәнни-технологик үсеш турында да онытмаска кирәк.

– Идел буе федераль округы төбәкләре илкүләм фәнни-технологик үсеш рейтингында чагыштырмача югары нәтиҗәләргә ирешә. Әйдәп баручы төбәкләр арасында Татарстан, Башкортстан һәм Ульяновск өлкәләре бар, – диде Дмитрий Чернышенко.

Киңәшмәдә төбәкләр алдына инвестицияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү,

tatarstan.ru

яңа эш урыннары булдыру, җирле һәм, гомумән, округ икътисадын үстерү кебек бурычлар куелды.

Самарага эш сәфәре кысасында Рөстәм Миңнеханов «Россия тимер юллары» ААҖ филиалы – Куйбышев тимер юллары җитәкчесе Вячеслав Дмитриев белән дә очрашты. Рәис билгеләп үткәнчә, Татарстан Куйбышев тимер юллары белән уңышлы хезмәттәшлек итә. Ел саен республикада тимер юл буйлап 15 миллион тоннадан артык йөк ташыйлар. Алдагы елларда йөк күләме тагын да артачак дип көтелә. Шуңа күрә яклар Татарстанда тимер юл инфраструктурасын үстерү турында да фикер алышты. Вячеслав Дмитриев Татарстан Хөкүмәтенә һәм шәхсән Рөстәм Миңнехановка тимер юл тармагына күрсәткән игътибары өчен рәхмәт белдерде.

УТЫРЫШ – 23 МАРТТА

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының кырык икенче утырышы 23 мартта узачак. Кичә парламент Президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 25 мәсьәләне, шул исәптән 16 республика законы һәм 4 федераль закон проектын карап тикшерергә җыена.

Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина билгеләп үткәнчә, көн тәртибенең төп өлешен федераль законнарга һәм Татарстан Конституциясенә туры китерү максатында эшләнгән закон проектлары тәшкил итә. Аерым алганда, Татарстанның кайбер законнарына үзгәрешләр кертү турында, шулай ук дәүләти гражданлык хезмәте, дәүләт символлары, Дәүләт Советы депутаты статусы турында республика законнары проектлары беренче укылышка әзерләнгән.

Моннан тыш парламент утырышында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү, энергияне сак тоту һәм аның нәтиҗәсен арттыру, азык-төлек иминлеге турында һ.б. республика законнарына үзгәрешләр кертүне күздә тоткан закон проектлары беренче укылышта карап тикшереләчәк.

Шулай ук кырык икенче утырышның көн тәртибендә «Балигъ булмаганнарның сукбайлыгын һәм хокук бозуларын булдырмау системасы нигезләре турында» федераль законның 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында федераль закон проектын Дәүләт Думасына тәкъдим итү буенча Татарстан Дәүләт Советы закон инициативасын карап тикшерү дә бар. Документ балалар арасында хокук бозулар санын киметү максатында әзерләнгән.

Утырышта депутатлар Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Рәисе каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең узган елдагы эшчәнлеге йомгаклары турында чыгышларын, Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы Баш идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүматларны да тыңлаячак.

Өебез җылы булсын!

Иртәгә – Торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре көне. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин тармак хезмәткәрләрен һәм ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре һәр көн саен миллионнарча кешенең тормышын уңайлырак һәм иминрәк итү өчен тырыша, – диелгән котлауда. – Сезнең профессионализм җәмгыятьнең тотрыклылыгын һәм тынычлыгын тәэмин итә. Һәрбер кешенең хезмәтегез нәтиҗәсен тоюы, сезнең ярдәмегез белән йортларыбызда уңай үзгәрешләрнең булып торуы күңелдә зур канәгатьлек хисләре тудыра.

Быел безгә республиканың шәһәр-авылларын төзекләндерү, авария хәлендәге торакта яшәүчеләрне яңасына күчерү, күпфатирлы йортларның, социаль объектларның инженерлык инфраструктурасын модернизацияләү һәм капиталь ремонтлау буенча зур эшләр башкарырга туры киләчәк. Халыкны чиста су белән тәэмин итү, җылылык казаннарын ремонтлау эше дәвам иттереләчәк.

Хөрмәтле коллегалар! Сезгә нык сәламәтлек, авыр эшегездә уңышлар, бәхет һәм иминлек телим!»

РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН:

«КРЕДИТ РЕЙТИНГЛАРЫ ҮСЕШНЕ БӘЯЛИ»

Бүгенге катлаулы вазгыять, илгә моңарчы күрелмәгән санкцияләр басымы шартларында Татарстан тотрыклы үсешен саклап кала. Моны Россиянең иң зур кредит агентлыклары раслады. Шул уңайдан «ВТ» хәбәрчесе Татарстан Республикасы финанс министры Радик ГАЙЗАТУЛЛИН белән әңгәмә корды.

:: Радик Рәүфович, күптән түгел генә Россия рейтинг агентлыкларының Татарстан кредит рейтингларын югары бәяләве турында хәбәр ителде. Бу җәһәттән сезнең фикерне дә беләсе иде.

– Чыннан да, «Эксперт РА» һәм «Аналитическое Кредитное Рейтинговое агентство» агентлыклары белән хезмәттәшлекне дәвам иттерәбез, һәм алар республиканың кредит рейтингларын раслады. Әйтергә кирәк, Россия Федерациясендә кулланылучы шкала буенча – иң югары дәрәҗәдә.

Һичшиксез, бүгенге вазгыять гадәти генә түгел. Геосәяси хәлләрнең кискенләшүе, Россия Федерациясенә карата дустанә булмаган чит илләрнең санкция басымы барлык төбәкләрнең икътисадына йогынты ясый. Шуңа да карамастан, Татарстан узган ел йомгаклары буенча социаль-икътисадый өлкәне эзлекле үстерүгә ирешә. Рейтинг агентлыклары билгеләп үткәнчә, республиканың кредит рейтингын шулай югары бәяләүгә төбәк икътисадының узган елдагы югары күрсәткечләре, сәнәгать һәм төзелештәге үсеш тә уңай йогынты ясаган.

:: Мәгълүм булганча, кредит рейтингларын билгеләүдә дәүләт бурычы күләменә зур игътибар бирелә. Татарстан Республикасы дәүләт бурычы турында сөйләп үтсәгез иде.

– Әйе, дәүләт бурычы күләме һәм аны түләү мөмкинлеге республиканың кредит рейтингына төп йогынты ясый. Тагын бер кат искә төшереп үтәм: февраль ае йомгаклары буенча республиканың дәүләт бурычы күләме 103,7 миллиард сум тәшкил итә. Шул ук вакытта аның

95 проценты – федераль бюджеттан алынган кредитларга, 5 проценты дәүләт гарантияләренә туры килә.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының банклардан алынган кредитлары һәм дәүләт кыйммәтле кәгазьләре буенча бурычлары, ягъни кыйммәтле капитал базары кредитлары юк. Моны да рейтинг агентлыклары уңай бәяли.

Республиканың дәүләт бурычы күләменә килсәк, аны, федераль бюджеттан алынган керемнәрне исәпкә алмыйча, Татарстан бюджеты керемнәре күләме (узган елда – 366,6 миллиард сум) белән чагыштырырга тәкъдим итәм. Бу күрсәткечләрнең нисбәте 28% чамасы тәшкил итә. Россия Финанс министрлыгы бәяләмәсе буенча, кулай күрсәткеч бу.

Шуны да әйтеп үтәсем килә: федераль бюджет кредитларын түләү вакыты бик озын – 2037 елга кадәр. Федераль бюджетка бурычларны озак вакытка реструктурлаштыру буенча 2012 елдан бирле үткәрелеп килүче эш нәтиҗәсе бу. Соңгы шундый уңай карарларның берсе – республиканың федераль бюджет кредитлары буенча бурычының бер өлешен түләү вакытын 2022 елдан 2029 елга күчерү.

Тагын бер уңай күренеш: узган елда федераль бюджет кредитлары буенча Татарстан бурычының бер өлешен (яңа инвестицион проектларны тормышка ашырудан кергән һәм федераль бюджетка җибәрелгән салым керемнәре күләмендә) гамәлдән чыгару башланды. Шул рәвешле 1,7 миллиард сумлык бурыч кичерелде. Алга таба да республика бурычын шул рәвешле кичерүнең дәвам итәчәгенә өметләнәбез.

:: Радик Рәүфович, чыннан да, сез сөйләгәннәрне бик уңай бәяләргә мөмкин. Ләкин бу урында бер әйберне ачыклап үтәргә кирәктер. Бездә капитал базарына мөнәсәбәтле бурычлар юк, дидегез. Әмма кемнәрдәдер шундый сорау туарга мөмкин: капитал базарыннан акча алмыйбыз икән, Татарстанга кредит рейтингы нигә кирәк?

– Кредит рейтингына ия булу үзмаксат түгел. Тотрыклы икътисадый үсеш шартларында республиканы кредит рейтингы агентлыкларының югары бәяләве, һичшиксез, төбәгебез икътисадына яңа инвестицияләр, республиканың зур предприятиеләренә чит илләрдән дә финанс ресурслары җәлеп итү өчен зур әһәмияткә ия булды.

Озак вакыт дәвамында кыйммәтле капитал базарына республика бюджетына өстәмә акча китерү өчен мөрәҗәгать итмәү җәһәтеннән шуны аңлатып үтәргә кирәк: Татарстанның икътисадый үсеше һәм бюджет сәясәте кыйммәтле кредитлар алудан коткарып килде. Әлбәттә, моны рейтинг агентлыклары күрми кала алмый.

Һичшиксез, бүген икътисадый өлкәдәге, шул исәптән финанс базарын үстерү перспективалары өлкәсендәге билгесезлек шартларында югары дәрәҗәдәге бәяне тынычрак кабул итәргә кирәк. Икенче яктан, әлбәттә, билгеле бер әһәмияткә ия бу. Шул рәвешле республиканың уңай имиджы булдырыла. Ә бу алга таба да республикада социаль-икътисадый вазгыятькә уңай йогынты ясаячак.

АЕРЫЛМАГЫЗ, АЕРЫЛМАГЫЗ...

Балалар омбудсменына мөрәҗәгать итүчеләр кимегән, өйдә белем алучы балалар күбәйгән, имин булмаган гаиләләр саны арткан. Бу хакта Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты утырышында Татарстанда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец сөйләде.

Гаилә кыйммәтләре һәм белем алу. Былтыр вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең күбесе әнә шул мәсьәләгә кагылган. Шулай ук татарстанлыларны торакка бәйле проблемалар, социаль тәэмин итү һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы мәсьәләләре кызыксындырган.

Гаиләләр таркалуны, ата-ана эчкечелеген, көнкүрештәге низагларны ничек булдырмый калырга? Утырышта бу хакта да фикер алыштылар. Сүз, нигездә, гаилә иминлеге турында барды. Ирина Волынец сүзләренчә, узган ел ул җитәкләгән оешма адресына 1758 мөрәҗәгать килеп ирешкән. Узган елдагы белән чагыштырганда, бу якынча 20 процентка кимрәк. Тикшерүгә 358 мөрәҗәгать алынган, шуларның 53 проценты уңай хәл ителгән.

Мөрәҗәгатьләрнең күбесе гаиләләрдәге катлаулы вазгыятькә бәйле.

– Мондый хәлнең төп сәбәбе – гаилә иминлеге булмау, – ди Ирина Волынец. Проблемалы гаиләләрдә үсүче балалар саны 6 процентка диярлек арткан. Хәзерге вакытта республикада ведомствоара исәптә 1,3 меңнән артык имин булмаган гаилә тора, аларда 2,7 меңнән артык бала тәрбияләнә. Узган ел 112 системасы буенча кергән мөрәҗәгатьләрне алсак, аларның 15 меңнән артыгы балигъ булмаганнар катнашында бәхетсезлек очраклары, балаларга карата көч куллану, аларга карата кылынган җинаятьләр хакында.

Гаиләдәге проблемалар буенча сорауларның күпчелеге бик четерекле. Әйтик, ата-ана аерылышканнан соң, балаларны тәрбияләү мәсьәләсе дә кискен булып кала. «Гаилә – төп кыйммәт», – дип саный Ирина Волынец. Вәкаләтле вәкил, аерылышуны булдырмау һәм гаиләне саклап калу өчен, медиатор (бәхәсне чишәргә ярдәм итүче кеше, психолог) ярдәменнән файдалануны мәҗбүри итәргә кирәк дигән фикердә.

– Проблеманы хәл итүгә медиатор алынганда, 30 процент очрак уңай хәл ителә, – диде ул.

Халыкны борчыган тагын бер мәсьәлә – белем алу хокукы. Оешма адресына килгән һәр бишенче мөрәҗәгать мәгариф мәсьәләсенә кагыла. Бу – балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә урыннар белән тәэмин итү, гомуми белем бирү учреждениеләрендә укыту шартлары һ.б. Депутатлар ике сменалы укыту турында да фикер алышты. Ел саен күп мәктәпләр төзелүгә карамастан, проблема актуаль булып кала.

Республикада өйдә белем алучы балалар саны да арткан. Гадәттә, мондый очракларда сүз мөмкинлекләре чикләнгән һәм психик тайпылышлары булган балалар турында бара. Тик башка проблемалар да бар: гаиләдә белем алуга күчү сәбәпләре арасында Ирина Волынец стресс һәм мәктәптә буллинг очракларын атады.

Ләйсән САФИНА

ЙӨЗ ЕЛЛЫК ОЧЫШ


АНТ-2

Пе-2



АНТ-20

Ан-2

Ту-104

Тарих битләреннән

Күптән түгел гражданнар авиациясе үзенең 100 еллыгын билгеләп үтте. Бу көн – безнең өчен дә зур бәйрәм. Чөнки Татарстан бу юнәлештә илебез үсешенә зур өлеш кертте һәм кертә.

Казан авиация институтын тәмамлап, хезмәт юлын беренче көннән үк Казан авиация заводында башлаган һәм бөтен гомерен диярлек шуңа багышлаган, бүлек җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелгән Рәфхәт Тәлгать улы Фазлыев, лаеклы ялда булса да, бүген дә самолетлар тарихы белән кызыксынуын ташлый алмый әле. Кайберләре, «иң-иң»нәре турында дип әйтик, безгә дә сөйләде.

Тәүгесе

Инде 1920–1930 нчы еллар башында ук совет авиаконструкторлары, һавада «Юнкерс», «Фоккер» кебек иномаркаларга көндәш булырлык очкычлар әзерләү өчен, булдыра алганның барысын да эшлиләр. АК-1 дип исемләнгән дүрт урынлы беренче совет пассажир самолеты 1923 елда конструкцияләнә. Аның тизлеге сәгатенә 146 км була һәм ул 2022 метрга кадәр күтәрелә ала. Дөрес, 1000 метр биеклеккә күтәрелер өчен шактый вакыт – 16 минут сарыф ителә. АНТ-2 исә тулаем металлдан эшләнгән беренче самолет була. Ул нигездә илебездә җитештерелгән материаллардан гына эшләнә. Шулай итеп, 1925 елда инде чит ил самолетларын бөтенләй диярлек кулланмый башлыйлар.

Күзгә күренмәс

Пе-2 самолеты беренче тапкыр 1928 елның 7 гыйнварында һавага күтәрелә. Барлыгы шундый 40 мең очкыч эшләп чыгарыла. Бөек Ватан сугышында искиткеч батырлыклар күрсәткән легендар самолет Казанда җитештерелә. Пе-2, реактив авиация чоры булуга карамастан, 1950 нче елларда Кореяда да сугышырга өлгерә. Америка очучылары аны «күзгә күренмәс» дип атыйлар, чөнки бу самолет бик түбәннән оча, реактив самолетлар һөҗүме өчен тизлеге дә акрын була. Фанера һәм тукымадан эшләнгәч, радарлар да тота алмый.

Искиткеч

«Максим Горький» исеме белән йөргән АНТ-20 дөньяда иң зур самолет була. Аны 200 (!) кешелек комиссия кабул итә. 1934 елның июнь аенда очкычны беренче тапкыр легендар очучы Михаил Громов һавага күтәрә. Ул аның турында «искиткеч самолет» дигән сүзләр әйтә.

Бу очкыч бортка 8 экипаж әгъзасын, 72 пассажирны ала. Әмма үзенчәлеге шунда: ул агитсамолет була. Аның бортына электростанция, кинопроектор, китапханә, типография урнаштырыла. Салон идәненә, каюталарга келәм җәелә. Буфет эшли.

Самолет 1935 елның 18 маенда фаҗигагә очрый. Кино төшерүчеләр үтенече белән авиатөзүчеләрнең гаиләләре өчен әзерләнгән очышта И-5 очкычы «Максим Горький» тирәсендә үлем элмәге ясамакчы була һәм аңа килеп бәрелә. Фаҗигадә дистәләгән кеше һәлак була, самолет шартлый.

Рекорд

Ан-2 – дөньяда бер моторлы иң зур биплан. Ул беренче тапкыр 1947 елның 31 августында очыш ясый. Гиннессның рекордлар китабына 70 ел буена берөзлексез җитештерелгәне өчен эләгә. Җитештерүне соңрак Кытайда дәвам иттерәләр. Самолет чын солдаттан ким булмый: чаңгыда да шуа, җирдә дә тәгәри, суда да йөзә. Командир үзе өстән күзәтеп, теләгән урынга төшереп утырта да ала.

НЛО

1956 елда беренче совет реактив пассажир самолеты Ту-104 Лондонга төшә. Көнбатышны СССРның мондый очкыч төзүе бер гаҗәпләндерсә, интерьерга карап, алар телсез кала. Британия матбугат чаралары аны НЛО, ягъни билгесез очу аппаратына тиңлиләр. Икенче көнне тагын бер Ту-104 килеп төшкәч, «Руслар самолет номерларын буяп, яңасын язалар», – дип тавыш чыгаралар. Шуннан соң Андрей Туполев Лондонга берьюлы өч очкыч җибәрергә куша.

Трап таба алмыйлар

Ике палубалы беренче совет очкычы Ту-114 1957 елда һавага күтәрелә. Ул дөньяда иң зур самолетларның берсе була. 1959 елда Америкага төшеп утыргач, 40 минут буена аңа туры килерлек трап таба алмыйча йөдиләр. Иң биеген китереп, өстенә баскыч куярга туры килә. Шул ук елның сентябрендә, шул ук борт белән Америкага Хрущев килә. Ул вакытта очкыч сынау чорын да үтеп бетермәгән була әле. Сынау да үтмәгән очкычка утырып, дәүләт җитәкчесенең чит илгә килүе тарихта беренче һәм соңгы очрак була.

Тавыштан да тизрәк

Тарихта тизлеге тавышныкыннан да югарырак булган Ту-144 пассажир самолеты 1968 елның 31 декабрендә һавага күтәрелә. Бу вакыйга аның көндәше – Англия һәм Франция җитештергән «Конкорд»тан ике ай элегрәк була. Совет лайнеры аңа караганда биегрәк, тизлеге зуррак һәм куәтлерәк. Әмма бер ягы бар: двигательләре ягулыкны яман да күп «ашый». Шуңа күрә, алдан уйланылганча, бу суперлайнерда Хабаровскига яки Владивостокка барып җитә алмыйлар. Иң ерак маршрут Мәскәүдән Алматыга кадәр була.

Футбол кыры хәтле

Ан-225 – дөньяда иң зур һәм иң авыр очкыч. Канатлары футбол кырына чак кына сыя. Бу гигант «Энергия-Буран» космик проекты кысасында барлыкка килә. 1989 елның май аенда ул «Буран» космик кораблен Париждагы авиасалонга алып бара һәм анда барысын да шаккатыра. Бу самолетның исәбендә 240 дөнья рекорды, шулар арасында – иң авыр йөк (253 тонна), иң авыр монолит йөк (188 т) һәм иң озын йөк.

Җирле халык өчен

Як-40 – җирле авиалинияләр өчен иң беренче өч двигательле пассажир самолеты. 1960 нчы елларда эшләнә. 1970 елда аның авторы Яковлевка Ленин премиясе бирелә. 1972 ел урталарына бу очкычлар 150 млн км ара үтеп, 7 млн пассажирга хезмәт күрсәтергә өлгерә.

Беренче номерлы борт

Ил-96-300 – ерак араларга очучы киң фюзеляжлы самолет. Россия Президенты өчен махсус җитештерелә. Бу лайнер – дөньяда иң куркынычсыз очкычларның берсе. Аңа кадәр Брежневтан алып Ельцинга кадәр ил җитәкчеләрен Ил-62 самолеты йөртә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Казан авиация заводы 1927 елның май аенда төзелә һәм хәрби, пассажир самолетларының яңа төрләрен җитештерү өлкәсендә гел алдынгы урыннарда була. Шушы еллар эчендә завод 34 төр авиация техникасы җитештерә. Алар арасында дөнья күләмендә билгеле Пе-2, Пе-8, Ту-16, Ту-104Б, Ту-22М3 самолетлары бар.

1936 елда авиапассажирларга хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшырту турында указ чыга. Самолетларда буфет барлыкка килә. Беренче стюардесса хезмәт күрсәтә башлый. Штат расписаниесендә ул кладовщик дип рәсмиләштерелә. Кайнар әбәт белән сервис Ту-104 самолетында 1956 елда оештырыла. Менюга ит, гарнир, яшелчә, сыр, колбаса, уылдык, май, җиләк-җимеш керә. Кайбер линияләрдә шампан шәрабе белән дә сыйлыйлар.

Ту-114


Ту-144

Ан-225

Як-40

Ил-96-300

Премьера

ТАТАРЧА «РЕВИЗОР»

Ришвәтчелек, казна малын туздыру, әшнәлек һәм куштанлык. Татар театры сәхнәсендә – безнең өчен бераз тансык булган сатирик комедия жанры. Тинчурин театрында татар әдәбияты классигы, драматург Нәкый Исәнбәтнең «Портфель» комедиясе буенча куелган «Аферист» спектакле премьерасы булды.

Рәмис Нәҗмиев

Тинчуринлылар Нәкый Исәнбәт иҗатына бу сезонда инде икенче тапкыр мөрәҗәгать итте. «Идегәй» спектакле Идел буе Болгар дәүләте халыкларының ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулуга багышланган иде. «Аферист»ка килгәндә, монда мәңгелек тема – ришвәтчелек проблемалары фаш ителә.

Спектакльнең инсценировка авторы – Илфак Хафизов, режиссеры – Илнур Гарифуллин. Рольләрне Илфак Хафизов, Ренат Шәмсетдинов, Алмаз Фәтхуллин, Зөлфәт Закиров, Альбина Гашигуллина, Зөлфия Вәлиева, Рөстәм Гайзуллин, Диләрә Фәттахова, Илнур Байназаров, Булат Зиннәтуллин башкара.

Вакыйгалар кечкенә генә Камышлау шәһәрендә бара. «Портфель», бер караганда, Николай Гогольнең «Ревизор»ын да хәтерләтә. Биредә барлык җитәкче вазыйфалар да кешенең сәләтенә, казанышларына карап түгел, ә туганлык һәм кода-кодагыйлык буенча бүленгән. Сүз уңаеннан, Нәкый Исәнбәт үзе моны «миргаянизм» дип атаган. «Гадел дәүләт – бер гаилә», – дип кабатларга яраткан Камышлау шәһәрендә яшәүчеләргә көтмәгәндә прокурорның килеп чыгуы аяз көнне яшен суккандай була.

Актерларның уены турында аерым әйтеп узарга кирәк. Сатирик комедия жанрына хас булганча, киемнәр, артистларның уйнавы без күреп гадәтләнгәнчә түгел. Элек швейцар булып эшләгәндә төрлесен күреп, шактый шомарган, эчеп, эшеннән куылган аферист, хәленнән килгәнчә прокурор Хизбулла Төхфәтуллин ролен «башкара», үзенең тар шәхси мәнфәгатен канәгатьләндереп йөри. Бу рольдә Илфак Хафизов уены шактый табигый килеп чыккан. Спектакльдә уңай геройлар да юк түгел. Нэпманнарны яшен кебек куркытып торучы авыл хәбәрчесе Зариф, комсорг Әүхәди рольләрен башкарган Булат Зиннәтуллин белән Илнур Байназаровны аерым билгеләп үтәргә кирәк. Бу геройларга пьесада күтәрелгән иң мөһим проблемаларның берсе – ришвәтчелек турында әйтү вазыйфасы йөкләнгән. Алар яңалык өчен көрәшүче көч буларак гәүдәләнәләр. Тере, кызып китүчән Камәретдин ролен башкаручы Зөлфәт Закировның табигый уены да тамашачылар күңеленә хуш килде. Катлаулы, чын прокурор ролен уңышлы башкарган Ренат Шәмсетдинов та спектакльне бер йодрыкка туплап торучыга әверелде.

Ялган прокурорны зур дәрәҗәгә күтәргән портфель спектакльдә аерым әһәмияткә ия. Хизбулла кулына очраклы рәвештә генә эләккән портфель кечкенә шәһәрдә яшәүчеләргә сихри тәэсир ясый. Режиссерның сюжетны заманга якынайтырга омтылганы да сизелә. Бер мизгелдә сәхнә өстендә берничә секунд очкан квадрокоптер әнә шул хакта сөйли.

– 1929 елда язылган булса да, Нәкый Исәнбәтнең әсәре хәзер дә актуаль. Бер гасыр үткән, әмма берни үзгәрмәгән. Шул ук куштанлык, ришвәтчелек. Нәкый Исәнбәтнең 80 битлек әсәрен 40 биткә калдырдык. Аның монологларын кыскарттык, күбрәк диалог форматында эшләдек. Бүгенгә яраклаштырып, темпны тизләттек, чөнки сатира жанры, хәзерге спектакльләр хәрәкәт, тизлек таләп итә, – ди инсценировка авторы һәм спектакльдә төп рольне башкаручы Илфак Хафизов. – Премьерадан соң өстәмә фикерләр, уйлар барлыкка килде. Әйтеп бетерә алмый калган фикерләр дә бар. Бераз шомартып, Алла боерса, алга таба тагын да матуррак, рәхәтрәк, җайлырак уйнарбыз, дип ышанып калам.

Татарстанның халык шагыйре Ркаил Зәйдулла фикеренчә, ришвәтчелек турында язган һәр әсәр актуаль булып чыга, беркайчан да искерми.

– Нәкый Исәнбәтнең «Портфель» әсәре аның пьесалары арасында күренеклеләрдән түгел. Ул Гогольнең «Ревизор» калыбында язылган. Исәнбәт ул вакыттагы НЭП заманын тәнкыйтьләгән. Тинчурин театры бу куелышта аны бүгенге заман белән бәйләргә омтылган. Россиядә менә шушы оятсызлык, куштанлык, ришвәтчелек кебек сыйфатлар һич югалмый. Безнең дә менталитет үзгәреп бетте. Болар турында язган һәр әсәр актуаль, берничә йөз ел искерми торган була. Куелышы, декорацияләре, музыкасы, артистларның уйнавы – барысы да ошады, – диде халык шагыйре. – Классикларыбызның әсәрләрен элек тә куялар иде. Әйтик, классик драматург саналган Тинчуринга татар театрлары даими мөрәҗәгать итеп тора. Исәнбәтнең беркайчан да онытылганы булмады. Ул – бик зур драматург, аңардан бөтен очракка туры килә торган пьесалар табып була. Классикларны укырга һәм аларны куярга кирәк. Тик бүген куела торганнарын әллә ни күп дип әйтмәс идем мин. Чөнки аларның күбесе Совет власте килгәч, идеологиягә корылган әсәрләр язган. Шуңа күрә монда пропорция сакланырга тиеш. Элекке драматургларны да, хәзергеләрен дә куярга кирәк. Әсәрләре сәхнәдә куелса гына, драматург үсә ала.

Спектакльне популяр татар җырчысы, «Изге ай» ансамбле солисты Халидә Бигичева да караган.

– Спектакльгә караганда миңа күбрәк тамашачы ошады. Залның шыгрым тулуы, матур итеп тыңлаулары, спектакльдән соң басып кул чабып озатып калуларына шатландым. Әле ярый үзебезнең татар телендәге татар спектакльләренә йөрүчеләр бар. Яшьләр дә күп килгән иде. Җаныма шулхәтле рәхәт булды, – дип, хис-кичерешләре белән уртаклашты җырчы. – Спектакльгә килгәндә, бөтенләй канәгать калдым дип әйтә алмыйм. Бәлки, ул безнең яшькә дә бәйледер. Яшьләр өчен бу – кызыклы, бик әйбәт спектакль. Аның үзенең тамашачысы бар һәм булачак.

Ләйсән САФИНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык икенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык икенче утырышын 2023 елның 23 мартында 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 17 марты
№ 1873-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык икенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык икенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2022 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында бала хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында» Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил доклады.
3. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 405-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 395-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчен югалтуын тану турында» 402-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 13^1 һәм 21 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 401-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 400-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 10^4 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 412-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 404-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
11. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 397-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы территориясендә энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 406-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 408-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135^5 статьясына үзгәреш кертү турында» 398-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасы Экология кодексына һәм «Татарстан Республикасының азык-төлек куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 407-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 399-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 403-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 410-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
20. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең 2022 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында доклады.
21. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
22. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 288225-8 номерлы федераль закон проекты турында (коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарны камилләштерү өлешендә).
23. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 293721-8 номерлы федераль закон проекты турында (балалар белән эшләү һәм яшьләр хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне төгәлләштерү өлешендә).
24. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{11} статьясына үзгәреш кертү турында» 287036-8 номерлы федераль закон проекты хакында» (җир кишәрлеге бирүдән баш тартуның өстәмә нигезләрен билгеләү өлешендә).
25. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3^7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 286758-8 номерлы федераль закон проекты турында» (гражданнарның гаражлар урнашкан җир кишәрлекләренә хокук алу мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 17 марты
№ 1874-VI ДС



Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯМЬЛЕ ЯЗ!

Ниһаять, табигатьтә яз исе... Чын язгыча көләшле һава торышы сөендерә башлады. Урамда рәхәт: җылы, тып-тып тамчылар тама, бөтен табигать кышкы йокысыннан уяна. Ә сез бу ел фасылы турында нинди беләсез? Үзегезне сынап карагыз әле.

1 **Яз айларында нинди бәйрәмнәр билгеләп үтелә?**
а) Белем көне;
б) Нәүрүз;
в) Республика көне.

2 **Җылы яктан беренче булып кайсы кошлар кайта?**
а) карлыгач;
б) сыерчык;
в) кара карга.

3 **Халык сынамышын дәвам иттер. Чыпчыклар чыркылдашса, ...**
а) көн җылытыр;
б) көн суытыр;
в) елгаларда боз тиз кузгалыр.

4 **Язның беренче чәчәкләре – ...**
а) үги ана яфрагы;
б) умырзая;
в) тузганак.

5 **Яз көне ... уяна.**
а) тал бәбкәләре;
б) тал песиләре;
в) март песиләре.

6 **Боз һәм кар эреде,**
Сулар йөгерде.
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.
Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?
Я, әйтеп кара.
Бу шигырь юлларының авторы кем?
а) Муса Җәлил;
б) Абдулла Алиш;
в) Габдулла Тукай.

Җаваплар: 1. б), 2. б). 3. а), 4. б), 5. б) 6. в).

МӘКТӘБЕМ – БЕЛЕМ УЧАГЫМ

Арчаның 2 нче номерлы гомуми белем бирү мәктәбендә «Алтын каләм» әдәби иҗат түгәрәге эшли. Яшь каләмчеләребез актив, һәр вакыйгага диярлек үз фикерләрен белдерәләр, шигырь, хикәяләр иҗат итәләр. Мәктәп елларының күңелләрендә матур хатирә булып калуына, шигырьләрендә чагылуына без дә бик сөенәбез.

Гөлнара МӨБАРӘКШИНА,
«Алтын каләм» әдәби иҗат
түгәрәге җитәкчесе

***

Әй, мәктәбем, белем учагым,
Тарихларга кереп каласың.
Җыелышып кайчан кайтсак та,
Колач җәеп каршы аласың.

90 ел ул – кыска вакыт түгел,
Уңышларга күмгән еллар ул.
Авыр хезмәт нәтиҗәсе аша
Белем хәзинәсен биргән ул.

Укытучыга бүген баш иябез,
Укучы белән без гел янәшә.
Дан-шөһрәткә, хөрмәткә төренеп,
Мәңге яшә, мәктәбем, яшьнә!

Зөһрә МУСИНА,
10 нчы сыйныф укучысы

ДИНӘ ХӨСНЕТДИНОВА:
«СПОРТ – ЯШӘҮ РӘВЕШЕМ»

Бүген бездә кунакта – фигуралы шуу остасы Динә Хөснетдинова. Ул, күптән түгел Кузбасста узган «Азия балалары» II кышкы Халыкара спорт уеннарында катнашып, 13–16 яшьлек кызлар арасында икенче урын яулап кайтты. Иң матур һәм нәфис спорт төре белән шөгыльләнүче кыз киләчәктә дөнья һәм Европа, Олимпия уеннары чемпионы булырга хыяллана.

Шәхси архивтан

:: Динә, бозга ничә яшьтә аяк бастың?
– Фигуралы шуу белән өч яшемдә шөгыльләнә башладым. Әти белән әни сүзләре буенча, мин кечкенәдән тиктормас, көчен, энергиясен кая куярга белмәгән бала булганмын. Шунлыктан алар мине фигуралы шууга биргән. Зәйдә нәкъ шул вакытта Боз сарае ачылган иде. Әтиемнең энесе дә шунда эшли иде. Шулай мин Зәйнең «Яшьлек» спорт мәктәбенә йөреп, спортның бу төре белән ныклап кызыксынып киттем. Миңа 10 яшь тулгач, гаиләбез белән Казанга күчендек. Монда килүгә, спорт мәктәбенә кердем. Хәзер мин Казанның «Стрела» спорт мәктәбендә шөгыльләнәм.

:: Әлеге спорт төре белән мавыгып китүеңә әти-әниең сәбәпче, димәк.
– Мине фигуралы шууга бирүләре өчен аларга шундый рәхмәтле мин! Кечкенә чакта балага этәргечне әти-әнисе бирергә тиештер, дип уйлыйм. Фигуралы шуудан башка тормышымны күз алдына да китермим хәзер. Шуның белән яшим, янып йөрим. Әти-әни дә миңа яраклашты инде хәзер (*көлә*).

:: Төрле дәрәҗәдәге бик күп ярышларда да катнашасың. Әле күптән түгел генә «Азия балалары» Халыкара спорт уеннарында 2 нче урын яулап кайттың.
– 7 яшем тулгач, республика күләмендә күп кенә ярышларда катнашып, призлы урыннар ала башладым. Казанда мин Надежда Заякина кул астында шөгыльләнәм. Надежда Владимировна күңелен биреп, безне җиңүләргә рухландырып эшли. Аңа рәхмәтем зур. Бер ел эчендә Татарстанның иң яхшы спортчы кызлары рәтенә кердем. Мәскәүдә һәм Сочида узган Россия Кубогы этапларында бишенче һәм алтынчы урыннар алдым. Быел Юниорлар арасында Россия беренчелегенә үттем. Россиянең иң яхшы 18 спортчы кызлары исемлегенә керттеләр. Шунда ярышып кайткач, «Азия балалары»на бардык. Азия, Россия һәм Белоруссиядән килгән 13–16 яшьлек 24 кыз арасында икенче урын алдым.

Кунагыбыз турында белешмә

- Динәгә – 13 яшь.
- Казанның Киров районындагы 4 нче гимназиянең 7 нче сыйныфында укый.
- Фигуралы шуу буенча Халыкара, илкүләм һәм республикакүләм ярышлар призеры һәм җиңүчесе.
- Россиянең һәм Татарстанның иң яхшы спортчы кызлары исемлегенә кергән.

:: Киләчәктә дөнья һәм Европа чемпионатларында катнашу, Олимпия уеннары чемпионы булу теләге дә бардыр?
– Һәрбер спортчының андый хыялы бардыр инде ул. Шул исәптән минем дә.

:: Бозга чыкканда үзеңне ничек хис итәсең? Дулкынланмыйсыңмы?
– Дулкынлану, борчылулар бозга чыгып басу белән югала. Миңа әтием белән әниемнең, якыннарымның, тренерымның җылы, кирәкле сүзләре стимул бирә, көч өсти.

:: Фигуралы шууда иң авыры һәм иң рәхәте нәрсә?
– Авырлыгы бар дип әйтә алмыйм. Иң мөһиме тырышлык, үҗәтлек кирәк. Ә рәхәте – куйган максатыңа ирешү. Спортчыны шул максатлар йөртә инде.

:: Үзеңне киләчәктә кем итеп күрәсең?
– Әлегә әйтә алмыйм. Әнием: «Тормыш фигуралы шуу белән генә барырга тиеш түгел», – дип әйтә. Уку да кирәк, матур итеп сөйләшә белү дә мөһим, ди. Мин аның белән килешәм, әлбәттә.

:: Уку дигәннән, укырга, башка кызыксынуларыңа вакытың каламы?
– Фигуралы шуу күп вакыт, көч таләп итә. Атнага 6 көн шөгыльләнәбез. Елына 20 көн генә ял итәбез. Ел саен җәй көне «сбор»ларга барабыз. Мәктәптә яхшы укыйм. Тик дәресләр дә калдырырга туры килә инде. Укытучылар аңлый, рәхмәт аларга. Шулай ук мин рәсем ясарга бик яратам.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Безгә язалар

КИТАПХАНӘ – ЯРАТКАН УРЫНЫБЫЗ

Кукмара районы Купка авылы мәдәният йортында урнашкан авыл китапханәсенең ишекләре бикләнеп тормый. Без, 4 нче сыйныф укучылары да, китапханәгә яратып йөрибез. Китапханәче Рәхилә апа Йөзмөхәммәтова яңа кайткан китаплар белән таныштыра. Китап укучылар белән төрле темага күзәтүләр, әңгәмәләр үткәрә, төрле әдәби кичәләр, викториналар, уеннар оештыра.

Китапханәдә балалар газета-журналлары белән без даими танышып барабыз, аларны бик яратып укыйбыз. Әйләнә-тирәне өйрәнү өчен, Рәхилә апа безне һәр ел фасылында экскурсияләргә алып чыкты. Анда үзебезнең туган авылны күзәттек. Табигать турында әсәрләр укыдык, әңгәмә кордык, төрле уеннар уйнап күңел ачтык. Туган ил, Ватан, күренекле якташлар турында да күп мәгълүмат тупладык. Рәхилә апа, мәктәпкә килеп, әфганчыларны искә алу буенча сыйныф сәгатендә дә катнашты. Анда ул авылдашыбыз Наил абый Латыйпов турында сөйләде. Ватан геройлары көнендә, Купка авылы башлангыч мәктәбе укучылары белән, Зур Сәрдек авылында туган Социалистик Хезмәт Герое Камил Шакировны искә алу уңаеннан китапханә дәресе үтте. Халыкара өлкәннәр көнлеге кысасында Рәхилә апа белән Купка авылында туып, шунда гомер итүче сугыш чоры баласы Нәкыйп абый Вәлиуллинның өенә барып кайттык. Без үзебез әзерләгән шигырь һәм җырларны башкардык. Нәкыйп абый да безгә үзенең җырларын башкарды.

Рәхилә апабыз безне шактый күп китаплар белән таныштырды, төрле очрашулар, кичәләр, түгәрәкләр оештырып, күңелебезне күрде. Хәзер ул лаеклы ялга чыкты. Без аңа нык сәламәтлек, гаилә бәхете, озын гомер теләп, зур рәхмәтләребезне җиткерәбез. Хәзер Купка авыл китапханәсендә Юлия апа Йөзмөхәммәтова эшли. Без аның белән якыннан танышырга өлгердек инде. Француз язучысы Шарль Перро тууга 395 ел тулуга багышланган китапханә сәгатендә күп мәгълүмат алдык. Без алга таба да күңелле очрашулар, кичәләр, түгәрәкләр булып торыр дип өметләнәбез.

Зилә ФӘТХРАХМАНОВА,
Зур Сәрдек гимназиясенең
4 нче сыйныф укучысы

Белеп тор!

Язгы киңәшләр

Яз – яңару һәм яшәрү вакыты. Әмма күпләрнең организмы әле кышкы йокымсыраудан уянырга ашыкмый. Кайбер кешеләргә яз төшенкелек хисе, хәлсезлек, күңелсез уйлар алып килә. Без сезгә язны яхшы кәеф белән каршылау серләрен өйрәтербез. Бу киңәшләр һәрберебезгә ямьле язның бар төсләрен, кояшын тоярга, йоклап калмаска ярдәм итәр.

СУ
йокыдан тизрәк арынырга ярдәм итә. Ул шулай ук кан тамырларына, тәнгә, нерв системасына яхшы тәэсир ясый.

ЙОКЫ
вакытында организмда бик күп процесслар бара. Күзәнәкләр аксымга байый, токсиннар өлешчә юкка чыга.

СПОРТ
Хәрәкәтләнү һәм активлык сәламәтлекне яхшырта. Физик күнегүләр организмны чыныктыра, йөрәк-кан тамырлары авыруларын киметә.

ДӨРЕС ТУКЛАНУ
Яз – организмда витаминнар җитешмәгән вакыт. Күбрәк җиләк-җимеш ашагыз, майлы ризыклар белән мавыкмагыз.

ЯҢА ХОББИ
Көннәр озынаю белән, яңалыкка омтылу барлыкка килә. Рәсем ясау, бакча серләренә төшенү, яңа спорт төрен үзләштерү файдалы булыр.

«Татар-информ»

Күңелле яңалык

«Апуш»ка – 1 яшь

Күптән түгел «Апуш» балалар театр студиясе «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә 1 яшьлеген билгеләп үтте. Узган елның 9 мартында шушы ук залда студиянең беренче дәресе үткән икән. Инде хәзер «Апуш»ның дәресләре өч мәдәният үзәгендә уза, студиягә йөрүче балаларның саны да берничә мәртәбә арткан.

Хәзерге вакытта Казанның «Сәйдәш», «Чулпан», «Ленин» мәдәният үзәкләрендә сезнең 86 яшьтәшегез шөгыльләнә. Туган көндә без аларның барысын да күреп кайттык. Әле үзләре белән сөйләшергә дә җай табылды. «Апуш» студиясе эшли башлаганнан бирле шунда йөрүче Фәридә Гатина бер ел эчендә үзенең бик үзгәргәнен әйтте.

– Үз-үземә ышаныч артты, татар телендә яхшырак сөйләшә башладым. Хәзер инде сәхнәгә чыкканда да ул кадәр дулкынланмыйм. Ә иң мөһиме – мин монда яхшы дуслар һәм шәп остазлар таптым, – дип сөйләде ул безгә.

«Апуш»ның туган көнен үз туган көннәреннән дә ныграк көтеп алган бу балалар. Сәхнәне дә дер селкеттеләр: җырладылар да, биеделәр дә, ел дәвамында әзерләгән спектакльләреннән өзекләр дә күрсәттеләр. Ә алар бер ел эчендә барлыгы 4 спектакль чыгарды – «Апушның тылсымлы төшләре», «Зоопарк-әлифба», «Әбугалисина» һәм «Кечтүк».

Туган көн тамашасына, зал тутырып, әти-әниләр, әби-бабайлар да килгән иде. Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, «Апуш»ның «әни»се Гүзәл Сәгыйтова аларга аерым рәхмәт әйтте.

Сүз уңаеннан, апушлылар тагын да ишәергә җыена: оештыручылар «Чулпан» мәдәният үзәге өчен өстәмә кастинг уздырачак. Кызганыч, төгәл вакытын әйтмәделәр. Әмма 1 ай эчендә тагын 10 бала сайлап алыначак. Казанда яшәүче балалар һәм әти-әниләр колагына монысы.

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 238

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+